Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № IV-8**

Балык Бистәсе штп. 2015 елның 28 октябре

2016 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты проектын төзү һәм раслау үзенчәлекләре турында

«2016 елга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары проектларын төзү һәм раслау үзенчәлекләре турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында» Федераль законның 3 статьясының үз көчен югалтуын тану хакында» 2015 елның 30 сентябрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 67 статьясындагы 4 өлеше таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИР:

1. 2016 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга:

1.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 81 статьясы нигезләмәләренең, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2013 елның 27 сентябрендәге XXVIII-2 номерлы карары белән расланган бюджет процессы турындагы Нигезләмәнең гамәлдә булуы, план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты проектын төзү һәм раслауга (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы карары проекты), Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советына күрсәтелгән проект белән бер үк вакытта Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы карарының план чорына документлар һәм материаллар тәкъдим итүгә карата (социаль-икътисадый үсеш фаразыннан, бюджет сәясәтенең төп юнәлешләреннән һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләреннән гайре);

1.2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 4,5 пунктлары, 6 пунктның алтынчы абзацы, 81 статьяның 12 пунктының унберенче абзацы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2013 елның 27 сентябрендәге XXVIII-2 номерлы карары белән расланган. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәнең 2 статьясындагы 1 пункты, 30 статьясындагы 2 пункты, 33 статьясындагы уникенче абзацының гамәлдә булуы.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының бюджет, финанслар, икътисад, җирле салымнар һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев